НОЯБРЬ, 2013 ЕЛ
№ 11 (030)

# Атна ВАКЫЙГАЛАРЫ

События НЕДЕЛИ

## НӘРСӘ? Кайда? КАЙЧАН?

### 180 метрлы шашлык?!

Казанда иң озын шашлыкны пешерү буенча дөнья рекорды куелды. Казан ярминкәсе биләмәсендә «Euro-Asia Expo-2013» Халыкара күргәзмәсе кысаларында узды ул шоу. 180 метр озынлыгындагы шашлык Казанда дөньяда беренчеләрдән булып пешерелде. Озынлыгы ягыннан гына түгел, ә хәләл сыер итеннән әзерләнгән булуы белән дә үзенчәлекле Казан шашлыгы. Аны пешерергә 200 кг ит һәм 500 кг күмер кирәк булган.

### Динә Россия Гимнын башкара


«Мосфильм» студиясендә Россия Гимнын яңача җырлап яздырдылар. Хорда Лариса Долина, Валерия, Александр Маршал, Олег Газманов, Алсу һәм башкалар белән якташыбыз Динә Гарипова да катнашты. Беренче канал хәбәр иткәнчә, Динә – башкаручыларның иң яше.

### Иң чибәр мөслимә

Индонезия башкаласы Джакарта шәһәрендә узган Халыкара «Мисс мөселман кызы 2013» бәйгесендә Индонезия, Иран, Нигерия, Брунея, Малайзия, Бангладеш һәм башка илләрдән мөселман кызлары катнашты. Алар Коръән уку, милли кием кию, Аллага ышануга инандыру, тәртиплелек буенча көч сынашты. Әлеге мәртәбәле титулны Нигерия кызы 21 яшьлек Обабийи Аиша Аджибола яулады.

### Мөселманнар чиркәү сатып алган

Бөекбританиядә яшәү өчен көрәшкән католиклар чиркәве мөселманнар өммәтенә сатылды. Соңгы вакытларда католиклар чиркәвенә халык бик йөрми башлаган һәм узган елның июлендә ул ябылган. Чиркәү өчен җаваплы Бирмингем архиепархиясе аны шушы ук урамдагы ике террасалы йортта гамәл кылучы «Мәдинә» мәчете мөселманнарына саткан. Хэнлидагы Изге Йөрәк чиркәве атакае Петр Вәзирби: «Чиркәү бинасының мөселманнар тарафыннан сатып алынуы гаҗәп түгел, чөнки бу районда ислам динен тотучы мөселманнар күп яши», – ди.



2 бит

## КАЗАН – спорт башкаласы



5 бит

## «СӘХНӘСЕЗ ДӘ яши алам!»

## Бу санда

### Алыштыргысыз КЕШЕ

**Шамил Закировның арабыздан киткәненә бер елдан артык вакыт узса да, сагындыра, юксындыра ул. Аның турында хатирәләр, истәлекләр.**



4 бит

### «Безгә аңлашу, АРАЛАШУ ҖИТМИ»



**Фатыйх Сибагатуллин: «Яңа татар хатын-кызы культы кирәк. Аннан, татар милли педагогикасы булдырылырга тиеш».**

6 бит

### Җилдән ТУГАНМЫ АЛАР?

**Суррогатлык... Нәрсә бу? Чарасызлыкта калганнарга ярдәмме, әллә үзенә күрә бер бизнесмы?**



7 бит

### Казан Олимпиада өчен ЛАЕКЛЫЛАРНЫ САЙЛЫЙ



**Сочида узачак Кышкы Олимпиада уеннарында бездән кемнәр катнашачак?**

8 бит

## Татарстан ХӘБӘРЛӘРЕ

### Президент чит ил татарлары белән очрашты

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Евросоюз территориясендә яшәүче ватандашлар белән очрашты.

Быел нигез салынган Европа Татарлары Альянсы рәистәше Венера Вәгыйзова ТР Президентына татар җәмгыяте активистларын тәкъдим итте һәм очрашуга алман татарлары гына түгел, ә Литва, Бөекбритания, Чехия һәм Франция татарлары да килгәнлеген ассызыклады. Европа Татарлары Альянсы рәисе Флюр Шәрипов Рөстәм Миңнехановка оешма турында сөйләде, аның милли үзенчәлекне саклап калу максаты белән эшләвен җиткерде. «Үзенчәлекне саклап калуы авыр, бигрәк тә чит җирдә. Иң мөһиме – туган җиренә, тамырларына рухи якынлыкны саклап калу. Республика җитәкчелеге тарафыннан, Татарстаннан чыккан татарлар белән элемтәләрне саклап калу өчен, барлык чаралар эшләнелә. «Ана теле» белем бирү проекты кертелде, «Алгарыш» программасы уңышлы эшли, Бөтендөнья татар конгрессы даими рәвештә эшли. Милләтнең интеллекты – безнең төп конкурентлы продукт, ул Татарстанга Россиянең иң инновацион үсеш алган төбәге булырга мөмкинлек бирәчәк», – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов очрашу соңында.

### Без – башкалар өчен үрнәк

ТАТАРСТАННЫҢ «Электрон хөкүмәт» проекты Россия төбәкләре өчен үрнәк.

Казанда «Мәгълүматлаштыру – Россия төбәкләрен камилләштерүнең нигезе» исеме астында илкүләм IT-форум узды. Чарада Россия Хөкүмәте вәкилләре белән беррәттән халыкара танылган компанияләр дә катнашты. Федерация Советында мәгълүмати җәмгыятьне үстерү буенча комиссия рәисе Руслан Гаттаров үзенең чыгышын «Электрон хөкүмәт» проекты белән бәйле мәсьәләләргә багышлады. «Электрон хөкүмәтнең бер төбәктә яхшы эшләп, икенче урында түбән дәрәҗәдә оештырылган булуы бер дә яхшы күренеш түгел. Безгә әлеге эшчәнлекне россиякүләм дәрәҗәдә бердәм итеп башкару кирәк», – дип белдерде ул чарага җыелган делегатларга. Әлеге проектның Татарстанда аеруча уңыш казанган булуы беркем өчен дә сер түгел. Руслан Гаттаров фикеренчә, республикада әлеге мәсьәлә, беренче чиратта, җитәкчеләрдә яклау тапкан. Татарстанның мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов сүзләренә караганда, республикада һәр секунд саен ике электрон хезмәт башкарыла. Шул рәвешле, халык аена 2,5 миллион хезмәтне интернет аша тормышка ашыра. Мәсәлән, 2012 елда татарстанлылар өчен 16,3 миллион электрон хезмәт күрсәтелгән.

### Ford Kuga Татарстанда җыела

«ФОРД» компаниясенә нигез салучының оныкчыгы Алабугада булды. Ул «Алабуга» МИЗда яңа автомобиль производствосын эшләтеп җибәрүдә катнашты.



«Алабуга» МИЗда «Форд-Соллерс» уртак предприятиесендә тулы цикл технологиясе буенча җыелган беренче Ford Kuga кроссоверы конвейердан төште. Тантаналы чарада ТР Премьер-министры Илдар Халиков, Ford Motor Company директорлары советы рәисе, компаниягә нигез салучы Генри Фордның оныкчыгы Билл Форд, «Соллерс» ААҖ генераль директоры Вадим Швецов катнашты. Ford Kuga Ford Explorerдан соң инде икенче кроссовер, ул, башка модификацияләрдән аермалы буларак, тулы цикл технологиясе буенча җыела. Бөтен дөньяда мондый производство бары ике җирдә: Алабугада һәм Штатта гына бар.

Татарстандагы яңалыклар турында тулырак мәгълүмат **shahrikazan.com** сайтында

# КАЗАН – спорт башкаласы

**2015 елда Казанда узачак Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионатына әзерлек кысаларында, Татарстан башкаласы башка халыкара һәм бөтенроссия дәрәҗәсендәге спорт ярышларын да кабул итәчәк.**



Алар хакында журналистларга Татарстан яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министры **Рафис Борһанов** сөйләде.

Спортның су төрләре сарайнда 14-19 ноябрьдә кыска аралыктагы суда йөзү буенча Россия чемпионатында 550 спортчының катнашуы көтелә. Чыгышларга 50 судья бәя бирәчәк, аларның 15е – Татарстаннан.

«Безгә әледән-әле төрле дәрәҗәдәге студент ярышларын үткәрү үтенече белән мөрәҗәгать итәләр», – дип белдерде Рафис Борһанов. Әйтик, киләсе 2014 елның июнендә Казан янә студентлар спорты башкаласына әверелергә мөмкин. 20 июньнән 6 июльгә кадәр биредә IV Бөтенроссия җәйге Универсиадасының финал өлешен үткәрү ниятләнә. Ярышлар 14 спорт төре буенча узачак. Казанга 2,5 меңнән артык спортчының килүе көтелә.

Рафис Борһанов сүзләренә караганда, киләсе 2014 елда Казан бадминтон буенча Европа чемпионатын кабул итүгә әзерләнә.

«Шулай ук киләсе елда фехтование буенча өлкәннәр арасында бөтендөнья чемпионатын уздыру нияте белән мөрәҗәгать итәләр. Бу Казанны спорт башкаласы буларак кына тану түгел, ә республиканың талантлы спортчылары белән тәкъдим ителгән фехтование мәктәбенә карата да мактау буларак кабул ителә. Моннан тыш, Казанда киләсе 2014 елда хатын-кыз командалары арасында су тубы буенча дөнья кубогы узачак», – дип хәбәр итте министр. Соңгы ярышлар FINA Халыкара йөзү федерациясе өчен сынау рәвешендә булачак. Су тубы спорт төре буенча хатын-кызлар 9-18 август көннәрендә көч сынашачак.

Министр әйтүенчә, җиңел атлетика федерациясе тарафыннан да үтенечләр күп. 2014 елда Казанда җиңел атлетика буенча Россия чемпионаты уздырылачак. «Моның өчен Үзәк стадион тулысынча әзер, Универсиада өчен аны реконструкцияләүгә 500 млн сум акча сарыф ителгән иде», – ди Рафис Борһанов. Ул шулай ук Казанда Россия яшьләренең II җәйге спартакиадасының финалы, ачык суда йөзү буенча ярышлар, хай-дайвинг буенча сынау ярышлары көтелүен билгеләп үтте.

# Тагын 13 МЕТРО СТАНЦИЯСЕ төзеләчәк



ТРның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Казан метросы үсешенә багышланган утырышта фикер алыштылар.

«Эшне «Имәнлек» станциясеннән башлап, 10 нчы микрорайон ягына хәрәкәт итәрбез дип исәпләп торабыз. Безнең төп бурыч – пассажирларга шәһәр буйлап хәрәкәтне уңайлы итү. Метро станцияләрен тизрәк төзесәк, Казан буйлап йөрү дә җайлырак булачак», – дип хәбәр иттеләр утырышта. Метроның икенче линиясендә 12 станция булыр дип ниятләнелә. «Имәнлек» станциясе исә 2015 елда кулланылышка тапшырылыр дип планлаштырыла. Ә менә линиянең тулысынча кайчан тапшырылачагын әйтүе кыен. Барысы да аны финанслаудан торачак.

«Казметрострой» МУП җитәкчесе Марат Рәхимовның хәбәр итүенчә, хәзерге вакытка «Имәнлек» станциясен төзүгә рөхсәт алынган һәм аның өчен 30 млн сум үзләштерелгән дә инде.

# ТАТАР РУХЫН читтә ничек сакларга?!.

**Чит төбәкләрдәге татар җәмгыятьләре җитәкчеләре Казанга җыелды. Татарларның федераль милли-мәдәни автономиясе алар өчен семинар-практикум оештырды.**

Узган ел шактый гына төбәкләргә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тарафыннан бишәр миллион күләмендә грантлар тапшырылган. Моның өчен җитәкчеләр Президентка һәм аны алырга ярдәм иткән өчен, федераль милли-мәдәни автономия җитәкчесе, Россия Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдиновка рәхмәтләрен ирештерделәр. Илдар Ирек улы аларга әлеге грантларны дөрес файдалану кирәклеген әйтте. Мәсәлән, шушы көннәрдә ул акчага Ульяновскида татарлар тарихына багышланган музей ачканнар. Самарага тапшырылган грант ансамбльгә киемнәр тектерүгә тотылган. Очрашуга килгән мәдәният министры Айрат Сибагатуллин җитәкчеләрне киләчәктә дә төрле проектларда катнашырга чакырды. Ул милли- мәдәни автономия җитәкчеләрен борчыган сорауларга да җавап бирде. «Сез Сабан туйларын оештырганда безгә зур ярдәм итәсез», – дип белдерде министр.

Мәскәүдән килгән белгечләр семинарда катнашучыларга ничек итеп социаль проектлар эшләү, грантлар алу һәм җәмәгать оешмаларының үз йөзен булдыру турында лекцияләр укыдылар. Җитәкчеләр, Мари Элда төбәкара татар милли-мәдәни автономиясенең эше белән танышу максатыннан, Йошкар-Олага барып кайттылар. ■

**Люция ГАЛИМҖАНОВА**

# «ТАТАРЛАР БУЛМАСА, Россия дә булмас иде»

**Россия стратегик тикшеренүләр институты җитәкчесе Леонид Решетников белән узган конференциядә шундый сүзләр яңгырады.**

Леонид Петрович, гомумән, татарлар турында матур сүзләрен кызганмады. «Татарлар – Россиянең өмете. Татарстан җимерелсә, Россия дә җир белән тигезләнәчәк. Шуңа күрә без Татарстан өчен көрәшергә тиешбез. Сер түгел: Татарстанда да экстремизм һәм ваһһабчылык кебек күренешләр тамыр җибәргән. Татарстан җитәкчелеге бу проблемалар белән көрәшә һәм нәтиҗәле генә эшләп дә күрсәтә», дигән фикерен аеруча Татар иҗтимагый үзәге әгъзалары хуплап кабул итте. Кайсы милләт кешесе генә туган телен мактаганнарын яратмас икән?!

Мәскәүнең Бирюлево вакыйгалары фонында Казанның толерант шәһәр булуы тагын бер тапкыр исбатланды. Рәсми мәгълүматларга ышансаң, бүген Татарстанда 173 милләт вәкиле гомер кичерә. 173 төрле дөнья, 173 төрле холык дигән сүз бит инде бу. Леонид Петровичның тагын бер фикеренә тукталмый калу мөмкин түгел. «Рус милләтчеләре мине гафу итсеннәр, тик Россия бер милләтле генә дәүләт була алмый. Илебезнең бөтенлеген саклау өчен без бергәләп тырышырга тиеш», – дип, республикабызның искиткеч зур ролен тагын бер тапкыр ассызыклады ул. Бу сүзләрнең ихласлыгы ышанасы, Татарстанның Универсиада үткәрүдән кала тагын нәрсәне дә булса «ура» кычкырырлык дәрәҗәдә башкара алачагына өметләнәсе килә. ■

**Фәнзилә МОСТАФИНА**

# ТУГАНЛЫК җепләре өзелмәсен!

Еш кына чит төбәктәгеләр Татарстанга кайткач, татар газета-журналларын, китапларын үзләре белән алып китәләр. Туган якташ еракта булганда татар матбугатын уку да жанга рәхәтлек, сагынуга дәва бирәдер, мөгаен. Татарстан яңалыклары белән даими танышып барырга, Казанга якынрак булырга телисезме? Хөрмәтле милләттәшем, бу мөмкин бит! Хәзер сезнең төбәктә дә Татарстан Республикасында басылып килүче «Шәһри Казан» газетасына язылырга була! Гыйбрәтле язмышлар, мәгънәле әңгәмәләр, татар авыллары тормышы, тагын бик күп синең өчен кирәкле мәгълүмат... Боларның барысын да «Шәһри Казан»нан укып бел! Туганлык җепләре өзелмәсен!

Шәһри КАЗАН
Чит өлкәләрдә язылу индексы – 25259
(*Россия каталогының төп нөсхәсенең* **33 нче битендә**).
Ярты елга язылу бәясе **280 сум**нан артмый.

# Ил күрке биеклегенә КҮТӘРЕЛГӘН ХӘЗРӘТ



Вагыйз хәзрәт Ярулин утыз ел буена миллионлы Самар каласында динебез исламга армый-талмый хезмәт итте. Вагыйз хәзрәт коеп куйган мулла гына түгел. Ул – олуг хезмәт юлын узган татар егете, татар ире. Менә шул нужа шулпасын эчеп, кыенлыкларны җиңеп, гаскәр хезмәтен үткәнгә дә 49 яшьлек ирне Самар татарлары шәһәребезнең бердәнбер мәчетенә имам итеп сайлап куялар. Шуның өстенә Вагыйз хәзрәткә Уфага барып Үзәк дини нәзарәтендә имамлыкка имтихан тапшырырга да туры килә.

Вагыйз хәзрәт Ярулин утыз ел буена башкаларны гына вәгазьләмәде, ул үз балаларыннан коеп куйган мөселман бәндәләрен үстерде. Тормышта иң читене – кеше баласын тәрбияләү түгел, иң авыры – үз балаңны татар итеп калдыру, мөселман итеп яшәтү. Менә шуңа да ул безнең өчен олуг үрнәк, зур шәхес, тәрбия өлкәсендә өлге.

Вагыйз хәзрәт Ярулинның Самарда динебез исламга хезмәт итүенә утыз ел узуына багышлап Самар Җәмигъ мәчетендә чәй табыны уздырылды. Табынга хәзрәтебезнең фикердәшләре җыелган иде. Барчасы да изге теләкләрен белдерделәр, аның сабырлыгына, түземлегенә соклану сүзләре әйттеләр, бүләкләр бирделәр.

Яңа Куйбышев шәһәренең имамы Әхмәткәрим хәзрәт гаҗәеп тирән мәгънәле бүләк тапшырды – бал. «Вагыйз хәзрәт утыз ел буена бөртекләп, берәм-берәм халыкны динебез ислам юлына бастырды. Ул җилкәсенә вазифаларны алганда өлкәдәге мәчетләр санын санарга кулдагы бармаклар җитә иде. Бүген аларның саны йөзгә якын. Самарның үзендә генә дә алты гыйбадәтханәдә намаз укыйлар. Самар Җәмигъ мәчетендә гаетләрдә биш мең кеше намазлыкта. Болар барчасы да Вагыйз хәзрәт Яруллинның хезмәт җимеше. Ул үз тирәсенә фикердәшләрен туплый алды, бал кортыдай уңганлык күрсәтте. Шуңа да хезмәтенең җимеше татлы», – диде Әхмәткәрим хәзрәт. ■

**Шамил БАҺАУТДИН**

# Татарстан КҮЧТӘНӘЧЕ

**Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы регионнарда телебезне, сәнгатебезне, мәдәниятебезне үстерүгә зур өлеш кертүче милли-мәдәни автономияләргә ярдәм йөзеннән грант бирү өчен милли проектларга бәйге игълан иткән иде.**



3 номинациядә уздырылган әлеге бәйгедә Республикабызның милли-мәдәни автономиясе дә катнашып, 7 проект тәкъдим итте. Шуларның икесе – «Яңарыш» газетасы әзерләгән «Хәерле иртә» тапшыруы һәм Удмуртия Республикасының социаль педагогия көллияте укытучысы Вәсилә Хәкимова җитәкчелегендәге «Этнокультуралы лагерь» проектлары җиңү яулады.

«Хәерле иртә» тапшыруы милләттәшләребезгә яхшы таныш. Быел аңа төгәл ун ел. Шул дәвер эчендә тапшыруга төрле үзгәрешләр кичерергә, авырлыклар белән очрашырга туры килде. Әлеге милли проектны саклап калу өчен күп көч куелды. Тик соңгы елда тапшыруның вакыты кыскару тамашачыларда зур канәгатьсезлек уяткан иде. «Минем Удмуртия» телеканалы җитәкчеләре, тапшыруның вакытын кайтару өчен, аның форматын тулысынча үзгәртергә кирәк дигән шарт куйдылар. Моңа кадәр матди мөмкинлекләр булмавы әлеге эшне туктатып торырга мәҗбүр итте. «Бәйгедә катнашып, грант алуыбыз – бик зур шатлык. Татарстан Республикасының рухи ярдәмен һәрвакыт тоеп яшибез. Инде рухи Ватаныбыздан матди ярдәм дә килү безгә эшләргә, яңа үрләр яуларга зур этәргеч бирә. Без әлеге бәйгене оештыручыларга, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына бик рәхмәтле. Хәзер без тапшыруны үзгәртә һәм аның вакытын кире кайтаруны таләп итә алабыз», – диде «Яңарыш» газетасының баш мөхәррире Рәмзия Габбасова.

Грант акчасына ике милли костюм, өр-яңа видеокамера, микрофоннар сатып алынды. Шулай ук тапшыруның бизәлеше дә үзгәртеләчәк. «Тапшыруны әзерләргә мөмкинлекләр булдырылды. Яңа видеокамера булгач, «Хәерле иртә» тапшыруының сыйфаты да яхшырыр дип өметләнәбез», – диде милли-мәдәни автономия җитәкчесе Равил Шәрифуллин. ■

**Эльвира ХУҖИНА**

# Оренбурның татар егетләре КАРБЫЗ ҮСТЕРӘ



**Татарлар күпләп яшәгән Линевка авылы – район үзәгеннән иң ерагы. «Безнең Линевкадан ил башлана», – дип шаяра Казахстан чигендә урнашкан авыл халкы.**

Бу як карбызлары белән горурлана. Быел буйлы җиләк үзенең яңа статусын – тауар билгесе бирү рәвешендә алды. Хәзер инде бу курорт шәһәре рәсми рәвештә Русиянең карбыз башкаласы буларак та танылды. 10-15 килограмм авырлыктагы карбыз, моннан да авыррак кабак – бу яклар өчен гадәти күренеш.

Оренбур туфрагы карбыз-кавын үстерергә бик тә уңдырышлы. Ә Тоз-Түбә карбызлары башкаларныкыннан татлырак булуы белән аерылып тора.

«Без «Холодок», «Крымсон» дигән карбызлар чәчәбез. Орлыкларны Волгоградның фәнни эзләнү институтыннан алып кайтабыз. Һәрбер сортның үз җитешү вакыты бар. Алар төрлечә пешкән кебек, карбызның өлгергәнен белү ысуллары да берничә», – дип сөйләде фермер Ранил Зәйтов. «Район үзәгеннән ерак торабыз. Шуңа да сыйфатлы карбыз-кавын үстерү безнең өчен бик мөһим», – ди фермер Ринат Мусин да.

Район үзәгеннән ерак яшәү хакларга да тәэсир итә, карбызның басудагы бәясе 2 сумга гына югарырак булса, базарда ул 4-5 тапкырга арта. Шуңа карамастан, карбыз эзләп килүчеләрнең саны кимеми. Татарстаннан, Башкортстаннан да карбызга килүчеләр өзелми. Җирле халыкның да күбесе сезонда акча эшләп ала. Милләттәшләребез фермерлык эше белән 7 ел шөгыльләнәләр, һәрдаим яңалыклар өстәп торалар икән. «Мускатный» дигән кавынны беренче ел чәчәбез, ул үзенең баллылыгы белән аерылып тора, бу сортны бик яраттылар, кабак та бу елны зур булып үсте. Боларны Сургут якларыннан да килеп алалар, ә без килгән һәр кунакны сыйлыйбыз, без килгән һәр кешегә шатбыз», – дип сөйләде Ринат Мусин. ■

**Фирүзә ӘБСӘЛӘМОВА**

# Яңа ТАТАР ҮЗӘГЕ

Долгопрудныйга Мәскәүдән электр поезды белән барып була. Шәһәрчек әле яшь, аңа бары тик 55 ел. «Аңа нигез салу эшләрендә, монда урнашкан заводларда хезмәт куюда татарлар да катнашкан.

Шуннан соң монда яшәп калганнар», – дип сөйли рәссам Ринат Курамшин. Ринат үзәкне ачу эшен башлап җибәрүче, Долгопрудныйга 1990 нчы еллар башында килеп төпләнгән. «Монда калып төпләнүчеләрнең оныклары татар үзәгенең ачылу тантанасына килделәр», – дип сөйли Ринат. Ачылу сентябрь ахырында узган. Хәзер татар мәдәнияте һәм сәнгать үзәге тулы көченә эшләп килә. Инде татар теле дәресләре башланган. Шулай ук биредә рәссамның шәхси күргәзмәсе, Россиядә яшәүче халыкларның милли киемнәре күргәзмәсе урын ала. Долгопрудный халкына да татар үзәге кызыклы. Алар монда экскурсияләр оештыра башлаган. ■

**Илдар ГАБИДУЛЛИН**

# ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ беренче тапкыр җыелышты

**Башкортстан Язучылар берлегендә бүген ике йөздән артык язучы әгъза булып тора. Шуларның 45е татар телендә иҗат итә. Шулай ук 70кә якын әгъза булмаган язучылар да бар.**

Уфада узган утырышта Язучылар берлеге рәисе Риф Тойгызов чыгыш ясады. Ул узган елда үткән язучылар корылтаен искә алып, беренче тапкыр рәиснең демократик шартларда сайлануын искә төшерде. Ул шулай ук берлекнең финанслану мәсьәләсенә дә тукталды: «Алдагы елга 4 миллион 100 мең сум акча бүленгән. Без бу акчага ел әйләнәсе эшли алмыйбыз. Шуңа берничә айга язучылар берлеге идарәсендә эшләүчеләр түләүсез ялга китәргә мәҗбүр булачаклар», – диде.

Утырышта тәнкыйть мәсьәләсе дә тикшерелде. Филология фәннәре докторы Әхәт Нигъмәтуллин тәнкыйтьнең булмавы, булганының исә макташуга корылуын билгеләде. Шулай ук Язучылар берлегенең интернет сәхифәсен булдыру, татар язучыларын интернетка кертү кебек мәсьәләләр дә каралды. Шуны да әйтергә кирәк, бүген Башкортстан язучыларыннан Галим Хисамов, Дамир Шәрәфетдиновның интернетта сәхифәләре, татар телендә иҗат итүче прозаик Дилбәр Булатова һәм яшь шагыйрь Руслан Сөләймановның «бите» бар.

Утырышта соңгы көн тәртибе буенча татар берләшмәсенең элекке рәисе Марис Нәзировның исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе дә каралды.

Башкортстан Язучылар берлеге каршында эшләгән татар берләшмәсе тарихында бу беренче җыелыш булды. Утырышта мондый чараларны һәр өч ай саен уздыру кирәклеге билгеләнде. ■

**Мөнир ВАФИН**

**Г.Камал театрының элекке директоры, танылган сәнгать эшлеклесе, күпләргә таныш шәхес Шамил Закировның арабыздан киткәненә бер елдан артык вакыт узса да, һәрчак истә ул, сагындыра, юксындыра, театрга барган саен аны күрәсе, сөйләшәсе килә.**



Шамил абый барысы өчен дә якын булды, ярдәм сорап килгән кешегә кулыннан килгәнчә булышты. Холкы шундый иде – кешеләр дип яшәде. Һәрбер кешенең шатлыгын уртаклаша, аның белән бергә куана белде, һәрбер кешенең фаҗигасен үзенең йөрәгә аша үткәреп, шәхси кайгысы итеп кабул итә белгән зур шәхес булды. Аның шәхси тормышы булмады да кебек, ул театр дип яшәде, ял көннәрендә дә ул Камалда иде. Корьән китаплары җыярга ярата иде. Алардан театр фойесында күргәзмә дә оештырды. Артистлар да театрда һәрвакыт тотрыклы тормыш булуы бары тик Шамил Закировка бәйле дип әйтәләр иде. Зур иҗади коллективны бердәм гаилә итеп тоту җиңел эшләрдән түгел, аның өчен һәр артист, һәр сәхнә артындагы эшче кадерле булды. Хезмәттәшләре, якыннары аны яратып, сагынып искә алалар:

# Алыштыргысыз КЕШЕ

**Зөлфирә ЗАРИПОВА,** Татарстанның халык артисты:

– Шамил Зиннур улы кебек игелекле кеше юк! Мин ялгыз бала таптым, аны үстердем, аның авырлыгын моны татып карады. Ул беркайчан да ... карагаан кеше генә белә. Ә Шамил аны аңлый иде. Улым белән мине машинасына утыртып, итальян кафесына алып барган иде, баламны туйганчы тәмле туңдырмалар, татлы ризыклар белән сыйлады, баланың күңелен күрде. Үзе дә шуңа сөенеп утырды.

Шамилне беренче тапкыр күрүем мәрхүмә Фирдәвес Хәйруллиналар белән бергә уздырган Яңа ел кичәсендә булды, ул да килгән иде, без ул вакытта – театр училищесы студентлары. Шамил Зиннурович бер почмакта кич буе тыйнак кына елмаеп утырды. Еллар үтте, зур дәрәҗәләргә җитте, ләкин шушы тыйнаклыгын югалтмады. Күңеле белән зыялы, асыл кеше булды. Шул беренче күрүдә үк аны яратып калган идем, гомерем буе күңелемдә аңа чиксез хөрмәтем булды.

**Вахит ИМАМОВ**, язучы:

– Мин Шамил Зиннур улын егет чагыннан бирле беләм. Ул беркайчан да үзгәрмәде, үзе булып калды. Һәрвакыт ихлас сокландым аңа: ул беркем дә башкармаган эшләрне башкарды. Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмәдә тупып-үскән кеше ул. Авылда әдипнең музеен булдыру, аның исемен, мирасын кайтартуда ул йөрде. Музей ачылышына танышлары белән бергә татарның 200дән артык күренекле шәхесен, Президентны кайтардылар, аларның җиңел кулыннан ел саен Гаяз Исхакый укулары оештырылды. Татар театры милләтне, телне саклап кала торган, узаңны үстерә, горурлык уята торган үзәк булып торырга тиеш дигәнгә инанган кеше иде ул, шул юнәлештән тайпылмады. Шамил Закиров күләгәдәге милли эшләр, милли мәдәният министры булды. Ул күп идеяләр бирде. Үзе уйлап тапканны тормышка да ашырды. Алыштыргысыз кешеләр юк, диләр, ләкин якын киләчәктә Шамил кебек шәхес барлыкка килерме?

**Әзһәр ШАКИРОВ,** Татарстанның, Россиянең халык артисты:

– Мин холкым белән дуамалрак кеше, буйсынырга яратмыйм. Ошамый икән – әйттем, еш кына каты да әйтәм. Шуңа күрә еш кына Шамил белән сүзгә дә килдек, бәхәсләшә идек. Ләкин үч саклау, үпкәләү булмады. Бәлки, хак та булмаганмындыр, ләкин Шамил мине кичерде. Ул күпләрне гафу итә иде, үзенә дә җиңел булмагандыр, ләкин иҗат кешеләренең күңелен аңлый иде. Башка мәсьәләләрдә сүзгә килгәләсәк тә, милләт өлкәсендә без фикердәшләр булдык. Аның милли хәрәкәткә күрсәткән игелеген санап бетерерлек түгел иде. Милләт өчен барысына да әзер булган шәхес иде ул. Шул сыйфаты өчен югары бәялим аны. Аның үлеме милләтнең фаҗигасе дип әйтмәс идем, чөнки ул күпне эшләп өлгерде, сәләтен кулланды. Халык аның кем икәнен белде, зурлады, рәхмәтле. Иртә китүе кызганыч булды, чөнки ул – кабатланмас шәхес.

Үлеме алдыннан, мәрхүмә Фирдәвес Әхтәмованың өчесен укыткач, без «Бабайлар чуагы» спектакле белән Яшел Үзәнгә бардык. Юлда ул үзен начар хис итте. Туктадык, дару бирдем. «Кайт, йөрмә безнең белән», – дидек. Спектакль барган чакта пәрдә артына карыйм, Шамил елмаеп, көлеп басып тора. Кайтканда ул Республика клиника хастаханәсе урынбасарының хәлен белергә кергән, ләкин шунда үзен тикшертмәгән. Аңа башкаларның сәламәтлеге мөһимрәк иде. Ә шунда кайтып үзенең дә гомере өзелә...

**Илфир ЯКУПОВ,** Г.Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры:

– Мине кул астына керткәч вакытта, аның авызыннан «алыштыргысыз кешеләр юк» дигән сүз ычкына иде, ләкин бу аның шәхесенә кагылмый. Театрны түгәрәк гаилә итеп тота алды, театрдагы һәрбер кешенең тормышын, проблемаларын белә иде һәм кулыннан килгәнчә ярдәм дә итте, булдырырга мөмкин түгел гамәлләрне дә башкарды. Андый кешене югалту – театр өчен зур фаҗига.

Ул үзе артыннан җайга салынган төзек система калдырды, барысы да сәгать кебек эшли. Мин үзгәртү кертмәдем, аңа тыкшыну зур гөнаһ булыр иде. Әмма Шамил абый заманнан артта калышмый иде. Ул яңа эш технологияләре куллану яклы булды. Быел без билетларны сатуны җирле электрон системга салдык, ул моны үзе дә теләде. Тиздән карта аша түләү дә эшли башлаячак, аннары интернет аша да сату җайга салыначак.

Камалда традицияләр көчле. Ел саен Марсель Сәлимҗановның туган көнен яңа премьера белән билгелибез. Шамил Закировның халык хәтерендә калуын телибез.

**PS.** *Казанда Иске татар зиратында җирләнгән милләтпәрвәр Шамил Зиннур улы Закиров каберенә күптән түгел һәйкәл куелды. 15 мартта исә аның туган көнендә Г.Камал театрында Шамил абыйны искә алу кичәсе оештырылачак, ул яраткан спектакльләрдән өзекләр булачак, аның дуслары чыгыш ясаячак.* ■

Материаллар «Азатлык» радиосы сайтыннан файдаланылды

---

## Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА:

# «ХУШЛАШМЫЙ китәм...»

**«Моңлы бала булдым тумыштан», – ди Гөлшат Зәйнашева үзе турында. Тукай районы Иске Теләнче авылында урта хәлле, нык тормышлы гаиләдә туса да, әти-әнисе, туганнары белән үсәргә насыйп булмый аңа.**

1930 елның язында НКВД ялчылары өйләренә бәреп керәләр дә, дошман, авыл кулагы дип, мылтык түтәсе белән төрткәли-төрткәли, балалары белән саубуллашырга да ирек бирмичә, әтисен төпсез караңгылыкка алып китәләр. Шул китүдән Хисам агай Соловки лагерьларында адәм баласы түзә алмаслык шартларда эшләп, чирләп вафат була. Күп еллар үткәч, репрессия корбаны булып аклана. Йорты тартып алынган, ризыксыз калган Зәйнашевләр гаиләсенә тормышны алып бару, очын-очка ялгау нык авырлаша. Әнисе Әнвәр апа ике яшь тә өч айлык Гөлшатны әтисенең бертуган сеңлесе Маһруй апага асрамага илтеп бирергә ризалаша. Шагыйрәнең бала һәм үсмер чаклары авыр сугыш елларына туры килә. Имеш, «халык дошманы» кызы булуы аның тормышына гел йогынты ясап тора. Казан педагогия институтында укыганда, НКВД таләп итә, дип аны укуыннан җибәрәләр. Әмма ул югалып калмый. Театр училищесында укуын дәвам итә. Хәер, актив, тырыш студент кызны институт директоры соңрак үзе эзләп табып кире укырга ала. «Халык дошманы кызы» дигән нахак мөһер аркасында, Язучылар берлегенә дә аны 1969 елда гына кабул итәләр. Гөлшат апа үз гомерендә шактый күп пьесалар: драмалар, комедияләр иҗат итә.



Гөлшат апа тормышта нык, көчле ихтыярлы, оптимист кеше иде. Тормыш аны тәрләчә, ә кайчак аяусыз сынады. Әмма ул бөгелмәде, бөтен авырлыкларны җиңеп алга омтылды. Республикабызның Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләген хатын-кызлардан беренче булып 1991 елда шагыйрә Гөлшат Зәйнашева алды. Ул бик өлгер, җитез, кыю иде. 55 яшендә җиңел автомобиль сатып алып, аны йөртергә өйрәнде, 70тә компьютерны үзләштерде, әсәрләрен шунда татар телендә яза иде. Дөнья малына, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы – таланты, сәламәтлеге, гаиләсе һәм дуслары, халык мәхәббәте булды. Бакчасында чәчәкләр үстерергә яратты, бигрәк тә хуш исле, ак төстәге сиреньнәрне.

Гөлшат җырга, музыкага булган мәхәббәтен кызы Асиягә дә йоктырды. Асия консерваториядә укып музыкаль белем алды. «Айсылу» балалар ансамблен оештырып, композитор Гөлнара Беляева белән бергәләп, әнисе Гөлшат апа сүзләренә язылган җырлар циклы дөнья күрде.

75 яшь тулган көнне Гөлшат апага инсульт булып, каты авырып китте. Ике ел дәвамында хастаханәдә дә, санаторийда да булды, әмма табиблар ярдәм итә алмадылар. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр аек акылында иде, кыенлык белән булса да сөйләшеп ятты. Янынннан кеше өзелмәде, балалары, туганнарыннан тыш бик күп дуслары аның хәлен белергә, кизү торырга килделәр.

Барчабызны тетрәндереп, якыннарын, чын дусларын тирән кайгыга салып, Гөлшат апабыз 2005 елның 1 апрелендә арабыздан китеп барды. Казанда Гөлшат Зәйнашева исемен мәңгеләштерү буенча күп эшләр эшләнде: башкала урамнарының берсенә Зәйнашева исемен бирү, музеен булдыру, шагыйрә турында истәлекләр китабын чыгару дисеңме... Гөлшат Зәйнашеваның татар җыр шигъриятендәге эшчәнлеген тирәнтен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясе дә якланды. Иң мөһиме, бакыйлыкка күчкәч тә Гөлшат апа милләтебез күңелендә яшәп калды. Җырлары-шигырьләре аша аны һәрдаим яныбызда тоябыз. Нәкъ үзе язганча:

*Тагын күрешергә булсын, хушлашмый китәм.*
*Искә алып, бер җырларсыз – җыр бүләк итәм.*

**Чын ир-ат эшләргә тиеш булганның барысын да башкарган ул – агачын да утырткан, гаиләсе өчен зур, зиннәтле йорт та салган, малай да үстергән. Иҗатта да моннан берничә дистә еллар элек яуланган биеклеген югалтмый – чөнки, үзе әйтмешли, күңелендә әле һаман гашыйк булу сәләте бар! Язмабыз Татарстанның халык артисты композитор Зөфәр ХӘЙРЕТДИНОВ турында.**



# «СӘХНӘСЕЗ дә яши алам!»

Питрәч районы, Татар Казысы авылында 11 балалы колхозчы гаиләсендә унынчы бала булып дөньяга килгән Зөфәр кечкенәдән шәһәргә китү турында хыяллана. Әмма әти-әнисе аны төп йортта калырга тиеш дип саный.

Төзүче булырга теләгән Зөфәр Казанда укырга кергәч тә, аны җибәрергә теләмиләр. Тик үҗәт егет барыбер үзенекен итә.

Төзүче дипломы булса да, Зөфәр җыр белән «агулана». Югыйсә, кечкенә чагында җырчы булу башына да килми аның. Ә менә институтта «хорга» йөрү – үзенекен итә. Шулчакта ул сәхнәгә халык җырлары белән чыга. Тыйнак егет хәтта үзе язган көйләрне дә Мансур Гыйльми тәхәллүсе астында яңгырата.

**– Авылдан килгән оялчан малай, мөгаен, мондый уңышлардан башы әйләнеп, «йолдыз» чире белән авырып алгандыр?**

– Әтинең бер бик акыллы сүзе бар иде: «Үзеңә бәяне дөрес биргәндә генә бу дөньяда дөрес яшәп була! Бу тормыш кредосына әйләнде – үз бәямне арттырмадым да, киметмәдем дә. Һәрчак теләгәнемне генә эшләдем. Иҗат итәсем килгәндә иҗат иттем, җырлыйсы килгәндә җырладым. Инде менә бүген җырларга ашкынып тормыйм. Сәхнәсез дә тыныч кына яши алам!

**– Ә менә җыр язмыйча яши алмыйсыздыр, мөгаен. Күңелдә көй тусын өчен ни кирәк?**

– Бары тик күңелгә ошаган шигырь тапкач кына җыр яза алам. Бик тиз туган җырлар бар, ошап та, берәр ел чиратын көтеп яткан шигырьләр бар. Көз һәм кыш айларында аеруча күп языла, җәй нишләптер иҗат туктап тора. Холкым белән авыл кешесе бит мин, төп нигездә калган энем янына кайтып, печән чабып, урманнарда йөреп килергә яратам. Иҗатташлык итмәгән бер генә автор да юктыр инде – танылган шагыйрьләрдән алып әле генә кулына каләм алган авторларга кадәр күзәтеп барам. Минем өчен иң мөһиме – оригинальлек. Һәр шагыйрьнең үз йөзе булырга тиеш!

**– Шигырь язарга иң зур этәргеч беренче мәхәббәттер, мөгаен. Ә композиторларга?**

– Яшь чакта бик идеалист идем – кешенең бер генә сөйгәне булырга, берәү белән йөрергә, шуңа гына өйләнергә тиеш дип уйлый идем. Әмма 6 елга якын очрашып йөргән тәүге мәхәббәтем, өч айга киткән җыеннан көтмичә, кияүгә чыгып куйган иде. Шул минуттан хатын-кызга булган ышанычым бетте, ул кавемгә бик ачулы идем. Аннан соңгы гашыйк булуларым 1-2 айдан озакка бармады. Әллә кызларның шундый җиңел холыклылары туры килгән, әллә күңелдәге яра артык тирән булган, берсен дә ярата алмадым. Очрашып йөргән кызларның исемлеге бик озынга китә башлагач, ашыгыч рәвештә өйләнергә кирәк дигән максат куйдым. Әтинең: «Ир-атны бозучы – ул хатын-кыз!» – дигән сүзләре дә тәэсир иткәндер, мөгаен.

**– Ә бит чын ярату сезне алда көтеп торган.**

– Өйләнергә карар кылгач, берәр тәртипле кыз белән таныштырыгыз әле дип, туганнарга мөрәҗәгать иттем. Шуннан абыйның «теща»сы (хатынының әнисе): «Әй, Зөфәр, күршебездә менә дигән бер кыз бар бит», – дип, күңелне кытыклап куйды. Әйткән сүз – аткан ук, мине әле генә балалар табибына укып кайткан Зөһрә белән таныштырырга булдылар. Кечкенә балалары чирли дигән булып, чакырып керттеләр күрше кызын. Баланы карады, тиешле дәвалау курсы язды да бу, мине күрмәмешкә салышып, чыкты да китте. Беләсезме, бу мин-минлегемә ничек тиде?! Ничек инде, мин әйтәм, каршында шундый егет утыра, ә ул күз дә салмый, янәсе. Шуның белән мине үзенә каратты да инде. Ярты ел йөрдек, егетеннән тартып алырга туры килде – барыбер үз дигәнемә ирештем, чөнки ул хыялымдагы бөтен яктан да камил хатын-кыз иде! Ә өйләнешеп бергә яши башлагач, аның беренче очрашудагы миңа булган битарафлыгының сәбәбен сорадым. Беләсезме ни дип җавап бирде: «Соң, Зөфәр, начар күрүемне беләсең бит, ә ул көнне күзлегем өйдә онытылып калган иде!» – диде. Вәт, мин җүләр капкамын!

**– Бөтен яктан килгән хатын-кыз, дидегез, әллә Зөһрә ханымның бер кимчелеге дә юкмы?**

– Аңа гел: иң зур кимчелегең – син артык акыллы, дим! Гаилә тормышы чалт аяз гына булмый бит, без дә күп сынау аша үттек. Аларны җиңел чыгып, бергә калырга Зөһрәнең миңа караганда да акыллырак булуы ярдәм иткәндер, мөгаен! Иҗат кешесе – хис кешесе бит инде ул. Әгәр гашыйк булу сәләтен югалтсаң, матурлыкка сокланудан туктасаң, иҗат үлеп үк бетмәсә дә, аның ике канаты киселә. Шуңа күрә без гел гашыйклык халәтендә яшәргә тиеш!

**– Хис кешесе дә, иң нык стресска бирешүче дә инде ул иҗат кешесе. Сезне рухи һәм физик яктан нәрсә формада тота?**

– Балачакта күрше малае белән «Рубин»да футбол уйнарга хыялландык бит без! Спортчы булу теләгемне артистлардан торган волейбол командасы оештырып чынга ашырдым бугай. Атна саен җыелып уйныйбыз, ярышларда катнашабыз. Җиңүләребез дә шактый! Футбол уйнарга инде хәзер хәл юк, әмма ул әле һаман иң яратып караган уен төре.

**– Тормышта барысы да сез теләгәнчәме?**

– Юк шул! Хыялымдагы зур йортны үз проектым буенча салып чыккач, әти-әнине дә алып килеп, шунда балалар белән бөтенебез бергә яшәрбез дип уйлаган идем. Ни кызганыч, өй төзегәнче әти-әни үлеп китте. Улым Зөлфәт өйләнүгә башка чыгу җаен карады. Инде кызыбыз Зиләбез дә башлы-күзле булса, өйдә хатын белән икәүдән-икәү генә калабыз...

**– Балаларның аерым яшәве, тормышта үз юлларын үзләре яруы хәерлерәктер ул!**

– Анысы шулай. Зөлфәт Финанс-икътисад университетын тәмамлап, уңышлы гына эшләп килә. Кызым юрист буларак карьера баскычыннан тиз генә күтәрелеп бара. Җәмгыятьтә үз урыннарын табу серләренә төшендерә алганбыздыр, күрәсең. Балаларның тәрбиясе, йөзгә кызыллык китермәүләре тулысынча әниләренең казанышы. Мин бит гомеремнең яртысыннан күбрәк өлешен гастрольдә йөргән кеше. «Ой, ничек зур үскәнсез!» – дип сөя идем балаларны кайткач. Гел юлда йөрсәм дә, үзем йорт кешесе, тыныч почмагың булу чиксез зур бәхет! ■

**Эльмира ҖӘЛИЛОВА,**
«Ирек мәйданы»

# КЫЗЛАР – йолдызлар!

**Тамырларында татар каны аккан кызларыбыз арасында дөнья күләмендә билгелеләре дә күп, шөкер. Алар югары үрләргә күтәрелгәндә, уңышларга ирешкәндә безнең дә йөрәкләр ирексездән горурлык хисләре белән тула. Tataram.ru порталы иң популяр булган татар кызлары рейтингын төзегән.**

Беренче баскычта гимнастка **Ләйсән Үтәшева** тора. Ул – «Comedy Club» резиденты Павел Воляга кияүгә чыгып, хәзер Роберт атлы малай үстерәләр.

Икенче урын **Эльвира Ибраһимовага** тәтегән. «Кабан күле хәзинәләре» фильмы прокатка чыкканнан соң, тулы метражлы нәфис фильмда баш рольләрнең берсен уйнаган телевидение алып баручысы күп кенә басмалар героинясына әйләнде.

Популярлык баскычында өченче урынны **Динә Гарипова** алды. «Евровидение» бәйгесенең финалы май аенда ук булуга карамастан, Динә әле Универсиада беткәнче журналист язмаларының төп герое булып кала бирде. Универсиада ябылышы тантанасыннан соң, Динәнең татар теленә тәрҗемә ителгән «What If» җырын күпләр уеннарның ябылыш тантанасы гимны да була алыр иде дип билгеләп үттеләр.

Дүртенче урын **Ирина Шейкныкы**. Аның Мадридның «Реал» командасы ярымсакчысы Криштиану Роналду белән романы тирәсендәге имеш-мимешләр бүгенгә чаклы тынмаган. Бу пар узган ел ук өйләнешергә тиеш булса да, туй булмады.

Иң билгеле татар кызлары бишлеген **Аида Гарифуллина** йомгаклый. Бүгенге көнгә ул Татарстаннан чыккан иң күренекле опера җырчыларының берсе.

Иң билгеле татар кызлары рейтингына тагын триумфаль Земфира, татар телендә җырлаучы Эльмира Кәлимуллина, хәйрияче Чулпан Хаматова, гаугачыл Роза Сябитова һәм эшлекле ханым Эльвира Нәбиуллина да эләккәннәр.



Аида Гарифуллина




Ләйсән Үтәшева



Эльвира Ибраһимова



Динә Гарипова



Ирина Шейк

# «БЕЗГӘ АҢЛАШУ, аралашу җитми»

**Көндәлек матбугат белән даими танышып бару аның канына сеңгән. Нәрсә яздылар икән дип кызыксынудан гына түгел, ни өчен язганнар, максаты нидә? Һәр язмадан Фатыйх Сәүбәнович Сибагатуллин менә шуларга җавап эзли. Соңгы араларда «Россия халыклары телләре» Законына үзгәрешләр кертү турында закон проекты хакында матбугатта бер-бер артлы язмалар басылгач та, фикерен белдерүне кирәк дип тапты. Әңгәмәбез менә шуннан башланды да.**



**– Хәлләр шулай ук тетрәндерерлек һәм төзәтелмәслекмени соң?**

– Һәр милләт гомер-гомергә үз язмышы өчен көрәшкән. Хәзер дә ул шулай. Сүз дә юк, көрәшергә кирәк. Әмма шушы юнәлештә эш иткәндә мин вакыт-вакыт аптырашта да калам. Безгә утырып бер сөйләшү, аңлашу, аралашу җитми. Мәскәү кыса дип лаф орудан гына мәгънә юк. Үзара аңлашу булмаса, Мәскәү кысачак та кысачак анысы. Милләтләр эшләре буенча комитет рәисе Хаҗиморат Сәфәралиевне, заманында Думада мәгариф комитеты рәисе булган Григорий Балыхинны, депутат Владимир Шемякинны сүгүдән генә дә эш чыкмаячак. Мин аларның өчесен дә яхшы беләм, мәсьәләне уртага салып сөйләшкәндә җайга килмәстәй, үз туксаннарын гына туглап торучы кешеләр түгел алар. Хаҗиморат Сәфәралиев, әйтик, үтә милли җанлы шәхес, гыйлем иясе – физика-математика фәннәре докторы, РАН академигы. Бернинчә көн элек Казанга кайтып матбугат белән танышкач, мин аның белән телефон аша элемтәгә кердем һәм закон проектына карата үземнең борчылуларымны белдердем. Ул да, мәсьәләнең җитди икәнлеген аңлап, октябрь аенда каралачак закон проектының ноябрьгә күчерелү ихтималы барлыгын һәм, аңарчы Татарстанга килеп, мәсьәләгә ачыклык кертү мөмкинлеген дә белдерде. Шулай итеп, бары тик Татарстан ягыннан гына омтылыш кирәк. Ни гаҗәп, моңарчы аның белән элемтәгә керүче дә булмаган. Сәфәралиев комитетында 8 депутат, әмма шулар арасында Татарстаннан ник бер кеше булсын?! Югыйсә без, татарлар, Россиядә сан ягыннан руслардан кала икенче милләт, дип күкрәк кагабыз, ә Россия Дәүләт Думасының милләтләр комитетында бер депутатыбыз да юк. Бу да уйланырга мәҗбүр итә торган факт. Алай гына да түгел, Думадагы 32 комитет җитәкчеләренең ник берсе Татарстаннан булсын?! Югыйсә, Думада иң күп – 15 депутат Татарстаннан. Бер регионнан да шулкадәр депутат юк. Элегрәк, рәис урынбасары Олег Морозов – безнеке, дип горурлана идек. Хәзер ул да китте һәм аның урынына Татарстан вәкилен тәкъдим итәргә бик мөмкин иде. Квота – безнеке. Моны мин Татарстан Дәүләт Советының кайгыртмавыннан гына күрәм.

Татар теленә әллә ни ис китмәгән мөнәсәбәт үзебезнең Татарстаннан ук башлана. Монда инде кемгәдер сылтау итеп торасы да юк. Әйтик, сессиядә депутатлардан кемнәр чалт иттереп татарча чыгыш ясый. Мәрхүм Туфан абый бар иде, ул да бик вакытсыз безнең арадан китте. Разил Вәлиевтән, Роберт Миңнуллиннан кала тагын кемне атый алабыз? Ни өчен сессияне татар һәм рус телләрендә алып бармыйлар? Чуашлар бит чуаш телендә алып бара.

Хәзер салым мәсьәләсен көйләү дә бик җитди булып көн тәртибенә килеп баса. Бүген Татарстанда җыелган салымның 28 проценты гына республикага кала. Бу бик аз. 45 процент турында сүз алып барырга вакыт җиткәндер дип уйлыйм. Һәм моның өчен бик күп мәртәбә Мәскәү юлын таптарга кирәк булачак. Элек донор төбәкләр 17 иде, хәзер 10га калды. Салым мәсьәләсен уңай хәл итү турыдан-туры милли сәясәткә дә килеп тоташты. Инде әйткәнемчә, көрәшсез булмаячак, әмма көрәш дигәннәренең куркыныч бер нәрсә түгел, уйланылган, акыллы, һәр ике якны да канәгатьләндерә торган булуы шарт. Шуңа иманым камил: безне аңлаучылар һәм аңларга әзер торучылар бар. Без – табигый байлыкларга бай һәм эшчән халкы булган республика. Мин яшь вакытларда, нефть утыз елга җитәчәк, дип сөйлиләр иде. Аннан соң инде утызы да, кырыгы да узды, шөкер, нефть ятмалары сөендереп тора. Галимнәр исәпләвенчә, нефть яңадан йөз елга җитәчәк. Хәзер битум нефте дә чыгарыла башлады. Нефтьле урыннар әледән-әле табылып тора. Димәк, төшенкелеккә бирелү өчен сәбәп юк. Республикада утыздан артык банк бар. Алар безнең республика халкы акчасы исәбенә эш йөртә. Бездәге банкка башка регионнардан килеп акча салмыйлар бит инде. Ник шул банкларны канун нигезендә инвестор итмәскә?

**– Фатыйх Сәүбәнович, Сезнең соңгы елларда милләт тарихына, милләт язмышына бәйле һәм галимнәр, гади укучылар тарафыннан бик яратып кабул ителгән китапларыгызда да халыкка мәгълүмат бирү белән бергә, аның өметле киләчәге хакында җитди фикер җиткерелә. «Татары и евреи» дигән китабыгызда аңлашылганча, яһүдләр һәрвакыт бер-берсенә ярдәм итәргә тора, татарда исә мондый әйбер юк кебек...**

– Моның сәбәбе, миңа калса, аналарга, гомумән, хатын-кызларга бәйле. Яһүдләрдә барысы да анадан тора. Акыллы, белемле генә татар хатын-кызларын күзәткәнем бар: әйтик, үзбәккә кияүгә чыксалар, балалары бөтенләй үзбәккә әйләнә, белоруска чыксалар – ул-кызлары бер кәлимә татарча белми. Татар хатын-кызлары ирләрен чиктән тыш ярата, аларга чиктән тыш тугрылыклы.

**– Ягъни татар хатын-кызлары яһүдиләрдән үрнәк алырга, ирләрен азрак яратырга тиеш дигән сүзме бу?**

– Хазар каганатында яһүдләр үзләренең иң чибәр, иң акыллы кызларын аксөякләргә кияүгә биргән. Кияү затлы, акыллы гына булсын. Шундый никахлар нәтиҗәсендә яһүдләр барлыкка килгән дә. Халыкның көче иң элек хатын-кыздан тора шул. Татар хатын-кызларының тәртибен үзгәртү буенча берәр программа кабул итәргә кирәктер алайса. Теләсә нинди милләт вәкилләренә кияүгә чыксалар да, балалары татар булып калсын өчен диюем. Татар кызлары өчен махсус мәктәпләр, махсус журналлар, кинофильмнар, социаль челтәрләр кирәк. Гомумән, яңа татар хатын-кызы культы кирәк. Аннан килеп, татар милли педагогикасы булдырылырга тиеш. ■

Габделбәр РИЗВАНОВ,
«Ватаным Татарстан»

## Татар ИЛЕ

*Ник бу кадәр сибелгән дә,*
*Таралган шулай татар?*
*Бар микән соң бу Рәсәйдә*
*Татар булмаган яклар?*

*Тын океан ярларыннан*
*Балтыйкка кадәр җирләр*
*Һәммәсе татар җире күк,*
*Һәммәсе безнең илләр!*

*Һәркайда татар мәкаме,*
*Һәркайда татар моңы.*
*Кытайга барып чыксам да*
*Очратам татарымны.*

*Ә Рәсәйме? Рәсәйнең һәр*
*Урысын кырып бак, бар, –*
*Корым астыннан ялтырап,*
*Килә дә чыга татар!*

*Урыс иле көчәйсен, дип,*
*Күпме көч куйган татар!*
*Сибелгән дә, таралган да,*
*Үз илен җуйган татар.* ■

Рафис КОРБАН

# Тел үлсә, ТАТАР ДА БЕТӘ

**Казанда «Туган телләрне һәм мәдәниятләрне саклау һәм үстерү» форумы кысаларында 6нчы Халыкара, 2нче Бөтенроссия конференциясе узды. Катнашучы 500ләп делегат арасында ерак һәм якын чит илләрдән: Германия, Кытай, Төркия һәм шулай ук Башкортстан, Кыргызстан, Казахстан, Үзбәкстан, Әзәрбайҗаннан, Россия төбәкләре вузларыннан филолог-галимнәр, аспирантлар, студентлар да бар иде, алар фикерләре белән уртаклашты.**




Төркиянең Эге университеты профессоры Мостафа Өнер, мәсәлән, бүгенге көндә туган тел бары тик сөйләшү теле булып кына калмаска тиеш, дип саный. «Тел – дәүләт теле, мәдәният теле булганда гына сакланып кала ала. Сан ягыннан йөз миллионнан азрак булган халыкларның телләренең бетү куркынычы бар. Әмма татар теленең нигезе бик көчле. Аның көчле орлыгы бар. Моны эшкәртергә генә кирәк. Интернетта татарча сүз язсаң, шундук аны табарга була. Моны байлык дип әйтер идем. Интернетта яшь буын татарча ни дә булса эшли, ни дә булса тарихка язып калдыра. Мин боларны күреп шатланам. Хәзер интернеттан бик күп газета укып була. Лингвистлар арасында, «Халык исән чакта тел үлә», дигән бер сүз бар. Халыкка бернәрсә дә булмый. Халык иминлектә яшәгәндә телнең үлү процессы дәвам итә. Халык, үзенең туган теле үлсә, башка бер чит телдән файдалана башлый. Татар теле туган тел буларак үлсә, татарлык та бетә бара дигән сүз.

Бүгенге көндә татар теле куркыныч пычак өстендә торган кебек.

Ә пычакның кайсы ягына килеп төшүе безнең кулыбызда. Татар телен саклау өчен аны укытып кына тукталып калмаска, ә яшь буынның миенә милли горурлыкны кертергә кирәк. Яшьләргә татар теленең кадерле тел булуын аңлатсак иде. Ягъни татарның пропагандасын ясарга кирәк», – ди галим.

Телләрне өйрәнү, бу өлкәдә милли элита булырдай кадрлар әзерләү юнәлешендә Татарстан Республикасы җитәкчелеге зур эш башкара. КФУның ФСИ директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов тиздән заманча җиһазландырылган, телләрне өйрәнүдә иң соңгы технологияләрне эченә алган Казан халыкара лингвистика үзәгенең тулы көченә эшли башлаячагын хәбәр итте. ■

(«Азатлык»,
«Татар информ»)

## ЧӘК-ЧӘК – баллы чикләвекләр

**400 г бодай оны, 4 йомырка, 70-100 г сөт, 10 г шикәр комы, бер чеметем тоз, ширбәт өчен 170 г бал, 100 г шикәр комы, пешерер өчен 200-300 г сары май.**

Камыр басабыз (катырак булсын). 1 см калынлыкта баучыклар әзерлибез, аны кечкенә чикләвек чаклы итеп кисәбез. Чикләвекләрне алтын төскә кергәнче эйләндереп майда кыздырып алабыз.

Балны шикәр комы кушып кайнатабыз. Әзер булганын белү өчен бер бал кашыгы кайнар ширбәтне салкын суга салабыз: баллы-шикәрле ширбәт йомшак шарга әйләнә. Чикләвекләрне тәлинкәгә салып, өстенә ширбәт сибәбез, таучык ясап, суынгач өстәлгә чыгарабыз.

# ҖИЛДӘН туганмы алар?

**«Борын-борын заманда әби белән бабай яшәгән, ди. Тату, бай яшәп тә боларның балалары булмаган. Менә әби камырдан күмәч пешереп, аңа күз-борын ясаган да мичкә тыккан»... Бу «Колобок» әкиятен белмәгән кеше юктыр. «Кар кызы» әкиятендә дә балалары булмаган әби белән бабай кар тәгәрәтеп бала ясыйлар.**




Балачагым әкиятләрен искә төшерү тикмәгә түгел. Безнең җырчы кумирларыбыз да узыша-узыша бала ясау белән шөгыльләнә башладылар бит. Филипп Киркоров берүзенә ике бала үстереп ята, ә балалар – әнисез. Җилдән туган, дигән гыйбарә бар бит әле, менә шул үзе түгелме соң бу? «Син алай итсәң, без болай итәбез», – дигәндәй, йолдызлар «анасы» Алла белән Максим да балалар «ясатканнар» бит. Ничек җайлы!

«Тапкан – ана түгел, үстергән – ана», – ди халык. «Кан барыбер үзенеке итә», – дигәне дә бар әле аның. Ләкин кешелек бүген күбрәк беренче гыйбарәгә таяна, ахрысы. Бала таба алмаучы гаиләләр өчен суррогатлык – балалы булу хыялын тормышка ашырырга ярдәм итүче бердәнбер юл, янәсе. Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар: кешеләр ни уйный, дин ничек ди?

Суррогат ана... Сәер сүзтезмә. Кешедә ничә ана була соң ул? Тугыз ай буе йөрәк астында йөрткән сабыен чит кешеләргә сатып җибәрүче хатынга «ана» дигән бөек исемне биреп буламы? Ә бу рәвешле дөньяга килгән бала дөреслекне белсә, кемгә «әни» дип дәшәр?

Интернет челтәрен ачып карасаң, анда суррогатлык хезмәтен тәкъдим итүче белдерүләр чиктән ашкан. Янәшәсендә «товар» бәясе дә «ялтырый»: 300 меңнән алып 1 миллионга кадәр, моннан тыш, ай саен түләнеп бара торган пособие дә бар. Кем өчендер бу үзенә күрә бер бизнес. «Баласыз гаиләләргә бәхет китерәбез», – дип аңлатырга тырышучылар да табылыр. Мондый бөек хисләр белән янгач, нигә аны акчага эшләргә? Болай да баласызлык кайгысыннан тилмергән, чарасызлыктан кая бәрелергә белмәгән ананың хисләреннән көлү, кесәсен сыгу гына түгелме соң бу? Хайваннарга акыл дигән нәрсә бирелмәсә дә, алар да мондый ук түбән дәрәҗәгә төшми...

Һәр бала үз ризыгы белән туа, дип, 7-8 бала үстергән әби-бабайларга аңлатып кара әле суррогат ана бала табып биргәнлекне. Җаваплары бер булыр: «Әстәгъфирулла, ахырзаман галәмәте». Бәлки, алар хаклы да булырлар, чөнки диндә суррогат ана дигән төшенчә юк. Диндә ясалма орлыкландыру рөхсәт ителә, ләкин бу никахлы ир белән хатын-кыз катнашында гына башкарылырга тиеш. Өченче якның кушылуы гөнаһ, тыела. Диндә бу зина (никахсыз җенси якынлык) кебек карала. Коръәндә: «Без сезне аналарыгыз карыныннан сабыйлар итеп чыгардык», – диелә («Хаҗ» сүрәсе, 5 нче аять). Бу сүрәдән ана белән баланың аерылгысыз икәне, һәр баланың бер генә анасы булуы аңлашыла.

Ислам тыйган һәрнәрсә хәерле. Күпме генә күз йомарга теләсәк тә, суррогат ана карынында бала барыбер канын, нәселен үзгәртә. Ә дин моңа кискен карашта. Бала турында да онытырга ярамый. Өч кеше катнашында «әвәләнгән» баланың сәламәтлеге, психикасы яхшы булыр дип беркем дә гарантия бирә алмый. Үзенең ничек дөньяга килгәнен белгәч, ата-анага булган хөрмәте юкка чыкса, тормыштан ваз кичсә, нишләрсең? Бәхетсез балалар болай да дөнья тулы...

Баласыз гаиләләргә күп акчалар түләп өсләренә гөнаһ алганчы, балалар йортыннан ул яисә кызны тәрбиягә алу хәерлерәк тә, саваплырак та булыр иде. Туганнан бирле тәрәзәдән мөлдерәмә күзләре белән эти-әнисен көтеп утыручы сабыйның сине күргәч елмаеп җибәрүен Аллаһ та күрә бит. Кем белә, бәлки, шул ятимгә яңа гаиләле тормыш бүләк иткәнең өчен, Аллаһы Тәгалә сиңа да киләчәктә күп балалы яңа тормыш бүләк итәр... ■

**Мәрьям АБДУЛЛИНА,**
«Шәһри Казан»

**Фирая САБИРОВА,** Казанда гаиләне планлаштыру һәм репродукция үзәге баш табибы:

– Суррогатлык яшәргә хокуклы. Аның турында нинди генә тискәре фикер әйтелсә дә, суррогатлыкның баласыз гаиләләр өчен бердәнбер чара булуын танырга кирәк.

**Йолдыз ШӘРӘПОВА,** шагыйрә:

– Мин бу нәрсәне бер дә хупламыйм. Баланы тугач ук ярата башлыйсың бит. Тугыз ай буена үз кисәгең булып беткән сабыйны ничекләр итеп башка кешенең кулына тоттырырга кирәк, Аллам сакласын! Баласыз гаиләләрнең ул соңгы өмете булып тора, билгеле. Әмма ничек кенә булса да, мин моңа каршы. Беренче чиратта мин монда суррогат әниләрне гаеплим, акча кирәк икән, аны башка юл белән эшләргә кирәк.

**Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВ,** «Казан нуры» мәчете имам хатыйбы:

– Дин буенча, суррогатлык тыелган дип беләм. Күптән түгел генә медицинаның шул өлкәсендә эшләүче табиб белән сөйләшергә туры килде. Ул, суррогат анадан туган балалар, имештер, эгоист булып үсә, аларда кызгану, жәлләү кебек хисләр булмый икән, дип сөйләп торды. Аллаһы Тәгалә сиңа бала бирмәгән икән, шуның белән килешергә кала. Аннан шунысы да бар: суррогат әнинең дә катышы булгач, ул баланы киредән бирмәскә дә мөмкин. Биргән очракта да, күңеле шул балада кала. Бу исә мөнәсәбәтләрне генә киеренкеләтә.




**Кеше вафат булганнан соң, аның рухына багышлап, нинди догалар укырга һәм кайчан?**

Үлгән кешенең рухына кайчан булдыра алсаң, шул вакытта дога кылырга ярый. Аның өчен Коръән хәтем кылырга яисә «Йәсин» сүрәсен укырга дигән сүз түгел. Нинди дога белсәң, шуны укысаң ярый. Бернәрсә дә белмисең икән, күп кенә итеп: «Ләәә иләәһә иллә Аллаһ, ләәә иләәһә илләллааһү», – дип әйтеп, «Йә, Аллаһым, зикеремне кабул кыл, әҗер-савапларын үземне тудырып үстергән ата-анам рухына ирештер, рухларын шат кыл. Атабыз Адәмнән алып бу көнгә кадәр булып үткән барлык мөэминнәрнең гөнаһларын ярлыка», – дип дога кыласың. Нихәтле күп кешеләрне искә алсаң, үзеңә шулхәтле әҗер-савап була, ди Пәйгамбәребез (с.г.в.).

**Аллага шөкер, быел да иртә яздан бирле мәш килеп, ару-талуны белмичә, сабый бала кебек карап-тәрбияләп, күп көч куеп үстергән яшелчә, җиләк-җимешләребезнең уңышы сөендерерлек булды. Аларны тыныч күңел белән җыеп алырга да насыйп әйләде. Үз бакчабызда үзебезнең хәләл көчебез белән үстергән булсак та, хезмәт җимешләребезне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән үстерә алганлыгыбызны да онытып җибәрмәсәк иде. Бары Аның кодрәте белән генә бер кечкенә генә орлыктан да чиләк тулырлык уңыш алабыз. Шуларга шөкер итеп, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтебезне белдереп, без дә бакча уңышларыннан мохтаҗларга өлеш чыгарырга тиешбез.**

# Гошер сәдакасы БИРЕР ЧАК...

Әлеге саваплы эш ислам динендә яхшы гамәл булып санала һәм ул гошер дип атала. Гошер сәдакасын күпме бирергә һәм аны кемгә тапшырырга? Әлеге сораулар белән без Казан ислам көллияте директоры урынбасары **Нияз хәзрәт САБИРОВ**ка мөрәҗәгать иттек.

– Гошер – ул зәкятнең бер төре. Аның төгәл нисабы (күләме) булмаса да, елга бер мәртәбә җыелган уңышның уннан бер өлешен фәкыйрьләргә бирү – фарыз (тиешле). Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа (с.г.в.) үзенең бер хәдисендә: «Җыеп алынган уңышның янгыр һәм елга сулары белән үстерелгән өлешеннән уннан берен, ә хезмәт куеп, ташылып су сибеп үстерелгән өлешеннән егермедән бер өлеше сәдака итеп бирелергә тиеш», – дигән. Ягъни мәсәлән, йөз чиләк бәрәңге алсагыз, аның ун чиләген гошер сәдакасы итеп бирергә кирәк була. Мохтаҗларга, ятимнәргә, сәламәтлеге булмаган кешеләргә, кем үз-үзен тәэмин итә алмый, шуларга өлеш чыгарсагыз, бик саваплы булыр иде. Гошерне элек-электән мәдрәсә шәкертләренә биргәннәр. Теләге булганнар аны мәдрәсәләргә китерә ала. Гошер сәдакасы ул малга бәрәкәт бирә. Гошер сәдакасын биреп, мин үзем ризыксыз калам дип уйлау дөрес түгел. Киресенчә, әгәр дә син гошерне генә түгел, гомумән башка сәдакаларны да ихлас күңелдән бирәсең икән, Аллаһы Тәгалә сиңа аны икеләтә кайтара. Шуңа омтылырга, ышанырга тиешбез. Аллаһның чиксез рәхмәте ихлас күңелдән изге гамәлләр кылучыларга бик якын. Ягъни саваплы эшләрне мине юмарт дип әйтсеннәр, мактасыннар әле дип эшләргә кирәкми, ул ихластан, Аллаһы ризалыгы өчен булырга тиеш. Шул вакытта гына аның нәтиҗәсен кеше бу дөньяда ук күрәчәк.

**– Гошер сәдакасын бирүнең билгеле бер вакыты бармы?**

– Гадәттә, аны көз көннәрендә, уңыш җыеп алынгач бирәләр. Көзнең кайсы аенда да ярый, соңрак бирү дә гаеп түгел.

**– Гошер сәдакасы итеп яшелчә һәм җиләк-җимешнең үзен түгел, ә алардан әзерләнгән кайнатмалар, салатлар рәвешендә бирергә мөмкинме соң?**

– Әлбәттә, ярый. Иң мөһиме – ниятең изге булу.

**– Бакчадан алынган уңышны, күчтәнәч итеп, туганнарыңа, хезмәттәшләреңә алып килү шул гошер сәдакасына булып кабул ителәме?**

– Бу күчтәнәч итеп кенә санала. Ул кеше күңелен сөендерү генә. Сәдака бит ул мохтаҗ кешеләргә генә бирелергә тиеш. Андыйларга бирү хәерлерәк һәм саваплырак. Әгәр дә туганың мохтаҗ икән, һичшиксез бирергә була.

**– Гошер сәдакасын бирмәү гөнаһмы?**

– Мөмкинлегең була торып, бирмәү – гөнаһ. Аны бирүдән курыкмаска кирәк. Аллаһы Тәгалә безгә биргән сәдакабызны берничә өлеш күбрәк итеп кайтарачак. «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятендә Ул: «Мин биргән нигъмәтләргә шөкрана кылсагыз, арттырып бирермен. Әгәр биргән нигъмәтләремә шөкрана кылмасагыз, газабым каты булыр», – дигән. Гошер сәдакасын биреп, без ярдәмгә мохтаҗ булганнарга шатлык китереп тә саваплы булабыз. ■

**Дилбәр ГАРИФ,**
«Шәһри Казан»



# КАЗАН Олимпиада өчен ЛАЕКЛЫЛАРНЫ САЙЛЫЙ

**Башкалабызда җәй көне шаулап-гөрләп узган Универсиада уеннарыннан соң, Татарстан спорты өчен чираттагы сынау Сочида узачак Кышкы Олимпия уеннары булачак. Анда катнашачак спортчыларның исемнәре инде билгеле. Әмма ТРның спорт министры Рафис Борһановның сүзләренә караганда, бу исемлек нәкъ менә катнашучыларныкы дип өздереп әйтергә иртәрәк.**


sport.ru.msn.com

Казан Сочида әле яшь булган «хаф-пайп» дисциплинасы кысаларында чыгыш ясаячак сноубордчы Артем Глебовны тәрбияләп үстерде. «Хаф-пайп» инглиз теленнән «торбаның яртысы» дип тәрҗемә ителә. Райдер үзенең трюкларын шушы махсус бөгелгән конструкциядә күрсәтә дә инде. Артем чаңгы спорты белән 2004 елда, әле ул Россиядә популяр булмаган вакытта ук шөгыльләнә башлаган икән. Бу егет үзлегеннән өйрәнүче буларак та кызыклы әле – чит ил райдерлары трюклары яздырылган видеолар буенча шөгыльләнеп өйрәнгән кеше бит ул. Илдә хәзерге көндә ярышларга әзерләнер өчен нибары 1-2 мәйдан гына бар. Казанда әлегә шартлар булмаганга күрә, Артем, шәхси тренерсыз гына, чит илдә шөгыльләнергә мәҗбүр. Егетнең сүзләренә караганда, Россия хаф-пайпта АКШтан күпкә калыша, әмма аны куып җитү мөмкин булмаган эш түгел.

Гомумән алганда, бүгенге көнгә Сочида узачак Олимпиадада катнашырга тиешле татарстанлылар исемлегендә – 9, паралимпиадада катнашырга тиешлеләрнекендә 3 кешенең исемнәре билгеле.

**Чаңгы ике төр ярышында (лыжное двоеборье):** Денис Исайкин, Нияз Нәбиев һәм Иван Панин.

**Чаңгы узышында (лыжные гонки):** Андрей Ларьков, Анастасия Доценко, Наталья Жукова һәм Алия Иксанова. Берсе дә чаңгы спорты белән кызыксынучылар өчен ят кеше түгел. Халыкара дәрәҗәдәге спорт остасы исемен йөртүче Алия быел Италиядә узган дөнья чемпионатында шәхси ярышларда уңышка ирешә алмады, аның каравы эстафета командасы белән бронза медаль яулады. 29 яшьлек Түбән Кама спортчысының Сочига бару мөмкинлеге зур дип бәяләнә. Анастасия Доценко да былтыр Италиягә барды, әмма медальсез кайтты. Ә менә узган ел ахырында булган Дөнья Кубогы ярышларында өченче урынны алды. Наталья Жукова исә былтыр Россия беренчелегендә 30 һәм 50 чакрым арага узган ярышларда беренче һәм икенче урыннарны яулады.

**Яңа төрләр:** җыелма команда данын ски-кросс төрендә Иван Аникин, хаф-пайп төрендә Артем Глебов яклаячак.

Тагын өч кеше **Паралимпия** җыелма командасына эләгү өчен дәгъва кыла. Болар – Әлмәттә туып үскән Рамил Илалетдинов, Сабадан Рушан Миңнегулов һәм Түбән Камадан Марта Зәйнуллина. Өчесе дә дөньяда иң көчле спортчылардан санала һәм моны аларның күрсәткечләре дә раслый. Әйтик, Рамил былтыр Швециядә узган дөнья чемпионатында өченче булган. Рушан өч ел элек Ванкуверда да чыгыш ясаган иде. Хәзер 21 яшьлек егетнең тәҗрибәсе тагын да артты. Марта исә былтыр Швециядә икенче булды.

# ИСЕРЕККӘ нотык


Бирмим мин сиңа, алкаш, бер читилек акча, көтмә дә. Тагын ләх булып исереп кайтмакчы буласыңмыни? Көлдермә, син алып кайткан хезмәт хакы үзеңә тыгынырга да җитми. «Кияүгә чыкмаска иде» дип... кем белгән синең гел исерек буласыңны?

Өйләнгәнче тәти егет булып артымнан калмый сыланып йөрдең бит. Башны тәмам әйләндердең. Болай икәнеңне белсәм, борылып та карамас идем дә. Дөрес, мәҗбүр итмәдең. Әмма утыз яшькә җиткәндә кияүгә чыкмыйм дип тәртәгә тибеп булмый шул! Менә шуннан файдаландың да инде син – аферист. Каян акча табып эчәсеңдер, мәлгунь! Алдама, дуслар гел эчереп тормый ул, үзеңнеке булмаса. Алай булгач, менә хәзер кая соң алар – ул хәсрәт дус-ишләрең? Миннән инде бер сәгать акча теләнәсең. Бетте, син кирәкмисең ул кабахәтләргә. Бер авызыңны тыялмагач, койрыгыңны кыс та җылы өеңдә ят.

Ачуымны китереп, кызгандырып маташма. Үзең сатып алган чир! Бирмим дип инде ничә тапкыр кабатладым. Исерек кенә түгел, саңгырау да бугай әле бу, эшләнеп бетмәгән нәмәстә! Чү нәрсә булды тагын? Идәнгә егылып китте. Йөрәге тотты микән әллә?.. Әй, син, исәнме? Тукта яңакларын чәбәкләп алыйм әле. Нашатырьда иснәтим, булмаса. Әстәгъфирулла, исән икән, күзләре ачылды. Уен-муен түгел. Җан тәслим кылуы да бар. Торып утыр, әйдә. Аякка гына сыларга дигән калдык аракым бар иде. Мә, йотып куясыңмы? Тик кара аны, бүтән өстәмисең! Бар булганы шул. Азрак тын ал да калган махмырыңны лапаста тирләп эшләп чыгарырсың. Анда син эчеп йөргәндә маллар колакларыннан букка батканнар. Хәлең бармы-юкмы, анда минем эшем юк. Коткарганга рәхмәт әйт. Булды, житте, сыйландың, әртис, хәзер – шагом марш үз ишләрең янына – абзарга! ■

**Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ**


karikaturist.ru



Нияз МИҢГАЛИЕВ төзеде

РФ территориясендә тарала торган «Атна вакыйгалары» («События недели») газетасының якынча гомуми тиражы – 90202 данә

**Атна вакыйгалары (События недели)**

Баш мөхәррир Мансур Газизҗан улы МОРТАЗИН

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» ААҖ, 420097, Казан, Академия ур., 2 нче йорт.
Редакция адресы: 420066, Казан, Чистай урамы, 5 нче йорт.
ТЕЛЕФОННАР: 8 (843) 562-50-12 – кабул итү бүлмәсе, 8 (843)562-50-07 – (факс).
Http://shahrikazan.com
E-mail: atna-vakiga@mail.ru

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2011 елның 9 мартында ПИ № ФС77-44149 нчы теркәлү таныклыгы алды

Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы. Газетада басылган язмаларны файдаланганда, шулай ук өзекләр китергәндә, «Атна вакыйгалары»ннан алынганлыгын күрсәтү сорала.

Газета аена 1 тапкыр чыга.